**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 22 июль № 500

г. Казань

Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплау максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\500.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 500 нче карары белән расланды

Юридик затларның
2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм юридик затларның 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарын каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү кагыйдәләрен билгели.

2. Субсидия 2013 – 2017 елларга гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча республика адреслы программасын тормышка ашыру кысаларында төзелгән торак урыннарга (алга таба – торак урыннар) милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнарны башкарган юридик затларга бирелә.

3. Субсидия тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы законда каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына (алга таба – Министрлык) расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия түбәндәге шартларга җавап биргән юридик затларга оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш) бирелә:

Татарстан Республикасы территориясендә законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән булу һәм эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру;

үзгәртеп оештыру, ябылу яки банкротлык стадиясендә тормау;

элегрәк бирелгән бюджет акчасыннан максатка ярашсыз һәм (яки) нәтиҗәсез файдалануны булдырмау;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларга мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмау.

5. Субсидия алу өчен юридик затлар Министрлыкка түбәндәге документларны кертә:

торак урыннар адресларын, торак урыннарга милек хокукын дәүләт теркәвенә алуны рәсмиләштерү белән бәйле чыгымнар күләмен һәм юридик затның реквизитларын күрсәтеп, субсидия бирү турында гариза;

торак урыннарга милек хокукын рәсмиләштерүгә чыгымнарны раслый торган һәм вәкаләтле вазыйфаи зат таныклаган түләү документлары күчермәләре;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына һәм дәүләт бюджеттан тыш фондларга мәҗбүри түләүләр буенча кредиторлык бурычлары булмауны раслый торган документ;

субсидия бирү турында гариза тапшырган көнгә юридик затка мөнәсәбәтле Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә ябылу, банкротлык, эшчәнлеген туктатып тору процедуралары булмау хакында юридик зат җитәкчесе имзалаган гарантияле хат;

юридик затның гамәлгә кую документлары, шулай ук алардагы барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре;

җитәкче вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре.

6. Юридик зат үз инициативасы буенча түбәндәге документларны кертергә хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында шаһәдатнамә күчермәсе;

салым органында исәпкә кую турында шаһәдатнамә күчермәсе;

Юридик затларның бердәм дәүләт реесрыннан өземтә.

7. Юридик зат бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларны кертмәгән очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

8. Министрлык теркәлгән документлар белән субсидия бирү турындагы гаризаны кабул итү һәм теркәүне алар кертелгән көнне гамәлгә ашыра.

9. Субсидия бирү турында яисә субсидия бирүдән баш тарту хакындагы карар субсидия бирү турындагы гаризаны кабул иткән һәм теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлык тарафыннан кабул ителә.

Кабул ителгән карар нәтиҗәләре хакында хәбәрнамә Министрлык тарафыннан юридик затка тиешле карарны кабул иткән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә язма рәвештә җибәрелә.

Юридик затка бирелә торган субсидия күләме аларга карата милек хокукын дәүләт теркәвенә алу рәсмиләштерелгән торак урыннар саныннан, торак урыннарга хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен дәүләт пошлинасы күләменнән, торак урыннарга милек хокукын беренчел теркәүгә тотылган акчадан чыгып билгеләнә.

10. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын кертү;

кертелгән документларда дөреслеккә туры килмәгән мәгълүматлар булу;

гариза бирүченең әлеге Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, юридик затка җибәрелгән хәбәрнамәдә баш тарту өчен нигезләр күрсәтелә.

11. Субсидия бирү Министрлык һәм аңа субсидия бирү хакында карар кабул ителгән юридик зат (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, максатчан билгеләнеше, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан кире кайтару очраклары һәм тәртибе, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәвенә тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга субсидия алучының (устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашкан дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләрдән тыш, шулай ук устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашкан коммерциячел оешмалардан тыш) ризалыгы күздә тотыла.

12. Министрлык килешүне төзегән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 14 көн эчендә субсидия алучының россия кредит оешмасында ачылган хисап счетына субсидияне күчерә.

13. Субсидия түбәндәге очракларда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

сусидия алучы субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертсә;

субсидия бирү шартлары үтәлмәсә;

субсидиядән максатчан файдаланмаса.

14. Килешүдә күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә юридик зат тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

15. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 13 нче һәм 14 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кайтару вакытларын бозган очракта, Министрлык субсидияне кайтару вакытлары чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны мәҗбүри кайтару буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә чаралар күрә.

16. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыра.

17. Юридик затлар Министрлыкка кертелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап тота.

---